Туктатып...
Яратып...
Кирәк икән протоколын
Язып бирә җан атып!

*Кушымта.*

## ДУСЛЫК ҖЫРЫ
Айрат Нәбиев көе
(Айдар Галимов репертуарыннан)

Таулар очып, елга кичеп
Җир чигенә барырмын.
Назга сусаган дусларны
Кочагыма алырмын.

*Кушымта*:
Чын дуслыкка киртә түгел
Биек Урал, Каф-таулар.
Дуслыкларны аералмый
Киң һәм тирән елгалар.
Берләштерә, дуслаштыра
Агыйдел, Сөн елгалар,
Җырлап кына узсын гомер,
Җырлап барсын дөньялар.

Дуслар булсын һәр җирдә дә,
Казанда һәм Уфада,
Самарларда, Чиләбедә
Мәскәүдә, Сарытауда.

*Кушымта.*

Чын дуслыкны еллар, юллар,
Матур җырлар ныгыта.
Чын дуслыкның чылбырлары
Йөрәкләр аша үтә.

*Кушымта.*

Йөрәкләрдән йөрәкләргә
Күпер салсын моң-җырлар.
Чын дуслыкка киртә түгел
Киң Иделләр, Каф таулар.

*Кушымта.*

## ЮЛДА КӨТСЕН ДУСЛАРЫҢ

Фәнир Галимов көе
(Фәнир Галимов репертуарыннан)

Бисмиллалар әйтеп, юл догасын укып,
Чыгып китәм озын юлларга.
Озын юллар — хәтәр, бәла килсә әгәр,
Таянам мин якын дусларга.

*Кушымта:*
Җиде юллар чатында
Җан дуслар көтеп торсын.
Кайнар чәйләр белән сыйлап
Җырлап озатып куйсын!